МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

01.07.2019 г.Казань № 507

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2019 елның 19 сентяберендә 5802 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2016 елның 21 июнендәге 348 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру һәм социаль, инженер һәм транспорт инфраструктуралары объектларының һәм социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүне дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту буенча дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру һәм социаль, инженер һәм транспорт инфраструктуралары объектларының һәм социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүне дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту эшен камилләштерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру һәм социаль, инженер һәм транспорт инфраструктуралары объектларының һәм социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүне дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту буенча дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламентын раслау турында» 2016 елның 21 июнендәге 348 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2017 елның 8 июнендәге 357 номерлы, 2017 елның 30 декабрендәге 909 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру һәм социаль, инженер һәм транспорт инфраструктуралары объектларының һәм социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүне дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту буенча дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү һәм
социаль яклау министрлыгының
2019 елның 1 июлендәге 507
номерлы боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2016 елның 21 июнендәге 348 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру һәм социаль, инженер һәм транспорт инфраструктуралары объектларының һәм социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүне дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту буенча дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр**

1 бүлектә:

1.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентларына карата төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) әлеге Административ регламентта каралган тәртиптә, «Россия Федерациясендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре турында» 2014 елның 29 декабрендәге 473-ФЗ номерлы Федераль законның 24 статьясында билгеләнгән тикшерүләрне оештыру һәм үткәрү үзенчәлекләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.»;

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруны җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге:

«Россия Федерациясендә гражданнарны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 181-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 27.11.1995, № 48, 4563 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1999, № 29, 3699 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – № 294-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2008, № 52, 6249 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре

турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2013, № 52, 7007 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Аерым эшчәнлек төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – № 99-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 19, 2716 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – № 152-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 31, 3451 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1999, № 14, 1650 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Азык-төлек продуктларының сыйфаты һәм куркынычсызлыгы турында» 2000 елның 2 гыйнварындагы 29-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2000, № 2, 150 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 19, 2060 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре турында» 2014 елның 29 декабрендәге 473-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 473-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2015, № 1, 26 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сәламәтлек саклау өлкәсендә, мәгариф өлкәсендә һәм социаль өлкәдә аларга карата планлы тикшерүләр билгеләнгән ешлыкта үткәрелә торган юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар тарафыннан гамәлгә ашырыла торган эшчәнлек төрләре исемлеген раслау турында» 2009 елның 23 ноябрендәге 944 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2009, № 48, 5824 ст.; 2011, №4, 614 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 30 июнендәге 489 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 489 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 28, 3706 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләрнең бердәм реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре турында» 2015 елның 28 апрелендәге 415 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 415 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2015, № 19, 2825 ст., кертелгән үзгәрешләрен

исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контролен (күзәтчелеген), муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнар тарафыннан алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре резидентларына карата уздырыла торган уртак планлы тикшерүләр турында» 2015 елның 22 октябрендәге 1132 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1132 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2015, № 44, 6127 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан документларга һәм (яисә) мәгълүматларга, шул исәптән электрон рәвештә, шушы документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмаларга гарызнамәләр җибәрү һәм аларны түләүсез нигездә алу турында» 2016 елның 18 апрелендәге 323 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 323 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2016 № 17, 2418 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Зарури таләпләрне һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтүләр төзү һәм җибәрү, юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан мондый кисәтүләргә ризасызлыклар бирү һәм аларны карап тикшерү, мондый кисәтүне үтәү турында хәбәр итү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 10 февралендәге 166 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2017, № 8, 1239 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контрольлек органнары тарафыннан зарури таләпләр, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләр бозылуны профилактикалау буенча чараларны оештыруга һәм гамәлгә ашыруга карата гомуми таләпләр раслау турында» 2018 елның 26 декабрендәге 1680 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2018, № 53, 8709 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контрольлек органнары тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында шушы документлар һәм (яки) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалардан сорала һәм алына торган документлар һәм (яки) мәгълүматлар исемлеген раслау турында» 2016 елның 19 апрелендәге 724-р номерлы күрсәтмәсе (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 724-р номерлы күрсәтмәсе) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2016, № 18, 2647 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль

законның аерым нигезләмәләрен тормышка ашыру хакында» 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы (алга таба – Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы) (Российская газета, 2009, 14 май, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Социаль хезмәтләр күрсәтү турында шартнамәнең үрнәк рәвеше турында, шулай ук социаль хезмәтләр күрсәтүнең аерым программасы рәвеше турында» 2014 елның 10 ноябрендәге 874н номерлы боерыгы (алга таба – Россия Хезмәт министрлыгының 874н номерлы боерыгы) (Российская газета, 2015, 12 гыйнвар, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Ияртеп йөрүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы (алга таба – Россия Хезмәт министрлыгының 386н номерлы боерыгы) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы www.pravo.gov.ru, 2015, 24 июль, бастырып чыгару номеры: 0001201507240003);

Россия Федерациясе Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Хезмәт, мәшгульлек һәм халыкны социаль яклау өлкәсендә инвалидларның һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең инвалидлар өчен үтемле булуы шартларын тәэмин итү һәм шул ук вакытта аларга кирәкле ярдәмне күрсәтү тәртибен раслау турында» 2015 елның 30 июлендәге 527н номерлы боерыгы белән расланган Хезмәт, мәшгульлек һәм халыкны социаль яклау өлкәсендә инвалидларның һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең инвалидлар өчен үтемле булуы шартларын тәэмин итү һәм шул ук вакытта аларга кирәкле ярдәмне күрсәтү тәртибе (алга таба – Россия Хезмәт министрлыгының 527н номерлы боерыгы белән расланган Тәртип) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы www.pravo.gov.ru, 2015, 18 сентябрь, бастырып чыгару номеры: 0001201509180024);

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «СНиП 35-01-2001. Биналарның һәм корылмаларның авыр хәрәкәтләнүче халык төркемнәре өчен үтемлелеге» СП 59.13330.2016 кагыйдәләр җыелмасын раслау турында» 2016 елның 14 ноябрендәге 798/пр номерлы боерыгы белән расланган СНиП 35-01-2001. Биналарның һәм корылмаларның авыр хәрәкәтләнүче халык төркемнәре өчен үтемлелеге. СП 59.13330.2016 кагыйдәләр җыелмасы (алга таба – СП 59.13330.2016 кагыйдәләр җыелмасы) (Норматив, методик һәм типик проект документлары турында мәгълүмат бюллетене, № 2, 2017);

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Россия Федерациясе территориясендә, Ерак Көнчыгыш федераль округы территориясеннән тыш, оештырылган алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентларына карата дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль органнар тарафыннан планнан тыш тикшерүләр уздыруны килештерү тәртибен раслау турында» 2016 елның 19 декабрендәге 817 номерлы

боерыгы (алга таба – Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 817 номерлы боерыгы) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы www.pravo.gov.ru, 2017, 21 март, бастырып чыгару номеры: 0001201703210041);

«Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2014 елның 18 декабрендәге 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 126-ТРЗ номерлы ТР Законы)(Республика Татарстан, 2014, 20 декабрь, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре» 2007 елның 15 августындагы 388 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2007, № 33, 1178 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруны оештыру тәртибен раслау турында» 2014 елның 25 ноябрендәге 909 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2014, № 93, 2872, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль хезмәтләрне күрсәткән өчен түләү күләмен һәм аны алу тәртибен раслау турында» 2014 елның 29 ноябрендәге 927 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2014, № 91-92, 2850 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр реестрын һәм хезмәтләрне алучылар регистрын формалаштыру һәм алып бару турында» 2014 елның 23 декабрендәге 1012 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр алучылар регистрын формалаштыру һәм алып бару тәртибе (алга таба – ТР МК № 1012 карары белән расланган Регистр формалаштыру һәм алып бару тәртибе) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2015, № 3, 0093 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 елның 29 декабрендәге 1053 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе (алга таба – ТР МК № 1053 карары белән расланган Өйдә социаль хезмәт күрсәтү

рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2015, № 7-8, 0201 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 елның 31 декабрендәге 1100 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе (алга таба – ТР МК № 1100 карары белән расланган Стационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2015, № 23-24, 0785 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар рәвешендә социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 елның 31 декабрендәге 1101 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар рәвешендә социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе (алга таба – ТР МК № 1101 карары белән расланган Ярымстационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2015, № 34-35, 1171 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып).»;

2 бүлектә:

2.3.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре резидентларына тикшерүләр уздыру сроклары 473-ФЗ номерлы Федераль законның 24 статьясының 4 һәм 8 өлешләрендә билгеләнгән.»;

2.4.1 пунктта:

5 абзацта «тиешле өлкәдә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан башкарма хакимиятнең федераль органы» сүзләрен «дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы эшчәнлегенең тиешле өлкәсендә» сүзләренә алмаштырырга.»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«2019 елның 1 гыйнварыннан башлап 2020 елның 31 декабренә кадәрге чорда үзләре турында белешмәләр кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясы нигезләмәләренә ярашлы нигездә кече эшкуарлык субъектларына кертелгән юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга карата планлы

тикшерүләр 294-ФЗ номерлы Федераль законның 26.2 статьясы таләпләренә ярашлы рәвештә оештырыла һәм үткәрелә.

Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре резидентларына карата планнарның проектларын эшләү, планнан тыш тикшерүләр уздыруны прокуратура органнары белән килештерү РФ Хөкүмәтенең 1132 номерлы карарында, Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 817 номерлы боерыгында билгеләнгән тәртипкә ярашлы рәвештә гамәлгә ашырыла.»;

2.4.6 пунктта:

«алдан тикшерү үткәрү барышында» сүзләреннән алда «кергән мәгълүматка» сүзләрен өстәргә;

«кирәк булганда, үзара бәйләнешкә кермичә гамәлгә ашырыла торган контрольлек чаралары үткәрелә» сүзләрен «кирәк булганда, үзара бәйләнеш кермичә контрольлек чаралары үткәрелә» сүзләренә алмаштырырга;

2.4.7 пунктта «зарури таләпләрне бозу турында яки (...) фактлары турында җитәрлек мәгълүмат алу» сүзләрен «фактлары турында җитәрлек мәгълүмат алу» сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлектә:

1 таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1 таблица - Социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләргә белдерелә торган зарури таләпләр исемлеге

| № п/п | Зарури таләпләр исемлеге | Зарури таләпне билгели торган норматив хокукый акт | Тикшерү үткәргәндә юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан күрсәтелә торган документлар |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Эшчәнлекне гамәлдәге норматив хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашыру, шул исәптән лицензияле булу. | № 442-ФЗ Федераль законның 12 статьясының 1 өлешендәге 1 пункты.<br>ТР МК № 1100 карары белән расланган Стационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 1.4.1 пункты;<br>ТР МК № 1101 карары белән расланган Социаль хезмәтләр күрсәтүнең ярымстационар рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 1.3.1 пункты | Социаль хезмәтләр күрсәтүнең аерым программасында билгеләнгән социаль хезмәтләр күрсәтү өчен матди-техник базаның, квалификацияле кадрларның булуын таныклый торган документлар (алга таба – ИППСУ). |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2. | Социаль хезмәтләрне алучыларга социаль хезмәтләрне ИППСУ нигезендә һәм социаль хезмәт алучылар яисә 442-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә аларның законлы вәкилләре белән төзелгән шартнамәләрнең шартларына туры китереп күрсәтү | №442-ФЗ Федераль законның 12 статьясының 1 өлешендәге 2 пункты, 16 статьясының 3 өлеше, 17 статьясы | Социаль хезмәтләр күрсәтүгә шартанмәләр; социаль хезмәт алучыларның формалаштырылган шәхси эшләре. |
| 3. | Ашыгыч социаль хезмәтләр күрсәтү. | № 442-ФЗ Федераль законның 12 статьясының 1 өлешендәге 3 пункты, 21 статьясы | Социаль хезмәтләрне алучының гаризасы, ашыгыч социаль хезмәтләр күрсәтелү турында бу хезмәтләрне алучы һәм җиткерүче турында, күрсәтелгән ашыгыч социаль хезмәтләрнең төрләре, вакытлары, датасы һәм аларны күрсәтү шартлары турында белешмәләре булган акт. Ашыгыч социаль хезмәтләр күрсәтелү турында акт |
| 4. | Социаль хезмәт алучыларга яисә аларның законлы вәкилләренә үтемле рәвештә бушлай нигездә аларның хокуклары һәм бурычлары турында, социаль хезмәт төрләре, аларны күрсәтү чорлары, тәртибе һәм шартлары турында, бу хезмәтләргә куелган тарифлар турында һәм социаль хезмәт алучы өчен аларның бәясе хакында яисә аларны бушлай нигездә алу мөмкинлеге турында мәгълүмат бирү. | № 442-ФЗ Федераль законның 12 статьясының 1 өлешендәге 4 пункты, 13 статьясы | Социаль хезмәтләр белән тәэмин итүченең социаль хезмәт төрләре, аларны күрсәтү чорлары, тәртибе һәм шартлары турында, бу хезмәтләргә куелган тарифлар турында һәм социаль хезмәт алучы өчен аларның бәясе турында яисә аларны бушлай нигездә алу мөмкинлеге турында локаль актлары. |
| 5. | Персональ мәгълүматларны яклау турында Россия Федерациясенең персональ мәгълүматлар турындагы законнарында | № 442-ФЗ Федераль законның 12 статьясының 1 | Шәхси мәгълүматларны эшкәрткәндә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | билгеләнгән таләпләр нигезендә социаль хезмәт алучылар турында мәгълүматтан файдалануга карата таләпләрне үтәү. | өлешендәге 5 пункты;<br>№ 152-ФЗ Федераль закон | куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча социаль хезмәтләр белән тәэмин итүченең локаль актлары |
| 6. | Татарстан Республикасында социаль хезмәт белән тәэмин итүчеләр реестрына кертелгән социаль хезмәт җиткерүчеләр тарафыннан Татарстан Республикасында социаль хезмәт алучылар регистрын формалаштыру өчен мәгълүматларны Министрлыкка үз вакытында тапшыру. | № 442-ФЗ Федераль законның 12 статьясының 1 өлешендәге 6 пункты, 26 статьясы;<br>ТР МК № 1012 карары белән расланган Регистр формалаштыру һәм алып бару тәртибенең 5 пункты | Социаль хезмәт алучыларның шәхси эшләре (социаль хезмәт алучылар регистрында социаль хезмәт алучылар турында мәгълүмат булу). |
| 7. | Ведомствоара хезмәттәшлек нигезендә балигълык яшенә җитмәгән балаларның ата-аналарын, опекуннарын, попечительләрен, бүтән законлы вәкилләрен кертеп, гражданнарны социаль күзәтүне, зарурлык булганда, медицина, психологик, педагогик, юридик, социаль яисә бүтән характердагы, шул исәптән мондый ярдәмне күрсәтә торган оешмаларны җәлеп итеп, гамәлгә ашыру. | № 442-ФЗ Федераль законның 12 статьясының 1 өлешендәге 7 пункты, 22, 28 статьялары | ИППСУ (социаль озата бару буенча аларда чагылдырылган чаралар белән) |
| 8. | Зарурлык булган очракта социаль хезмәт алучыларга медик-социаль экспертиза буенча федераль учреждениеләр тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә уздырыла торган медик-социаль экспертиза (алга таба – МСЭ) узганда, шул исәптән инвалидлык группасы билгеләү, үзгәртү максатларында, яисә инвалидны тернәкләндерүнең хосусый программасын төзегәндә, гражданинга таныклау узуда булышлык күрсәтүне, МСЭ юллама алу максаты белән медицина оешмаларында медицина таныклавын узуда булышлык күрсәтүне тәэмин итү, МСЭ уздырыла торган урынга социаль хезмәт алучыны транспорт белән китерүдә ярдәм итү, тернәкләндерү буенча хосусый программаны тормышка ашыруда булышлык күрсәтү һ.б. | № 442-ФЗ Федераль законның 12 статьясының 1 өлешендәге 12 пункты | ИППСУ (МСЭ үтүдә шартлар тудыру буенча аларда чагылдырылган чаралар белән) |
| 9. | Социаль хезмәтләрне ышанычлы күрсәтү. | ТР МК № 1100 карары белән расланган | Социаль хезмәтләр күрсәткәндә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Стационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 1.4.2-1.4.4 пунктлары;<br>ТР МК № 1101 карары белән расланган Ярымстационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 1.3.2-1.3.4 пунктлары;<br>ТР МК № 1053 карары белән расланган Өйдә социаль хезмәтләр күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 4.1 пункты | кулланыла торган җайланмаларның, материалларның ышанычлы булуы, нормаларга җавап бирүе турында документлар; социаль хезмәтләрне күрсәтү буенча кулланмалар, кагыйдәләр, технологияләр һәм методикалар; җитештерүдә контрольлек нәтиҗәләре, шул исәптән лаборатор тикшеренүләр һәм сынаулар үткәрү юлы белән. |
| 10. | Социаль хезмәтләрне сыйфатлы күрсәтү өчен кирәкле персонал булу | ТР МК № 1100 карары белән расланган Стационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 1.5.1 пункты;<br>ТР МК № 1101 карары белән расланган Ярымстационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 1.4.1 пункты;<br>ТР МК № 1053 карары белән расланган Өйдә социаль хезмәтләр күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 6.3.1 пунктчасы | Штат расписаниесе |
| 11. | Социаль хезмәтләр күрсәтүне туктатып торган яисә туктатканда нигезләрнең үтәлеше | ТР МК № 1100 карары белән расланган Стационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең1.7 пункты;<br>ТР МК № 1101 карары белән расланган Ярымстационар рәвештә | Социаль хезмәт алучыларның шәхси эшләре. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 1.6 пункты;<br>ТР МК № 1053 карары белән расланган Өйдә социаль хезмәтләр күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 4.6 пункты | |
| 12. | Күрсәтелә торган социаль хезмәтләрнең сыйфаты билгеләнгән таләпләргә туры килү | ТР МК № 1100 карары белән расланган Стационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 1.8 пункты;<br>ТР МК № 1101 карары белән расланган Ярымстационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 1.7, 3.3 пунктлары;<br>ТР МК № 1053 карары белән расланган Өйдә социаль хезмәтләр күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 6.4 пункты | Социаль хезмәтләр күрсәтү журналлары, хисап формалары һәм социаль хезмәтләр белән тәэмин итүченең локаль актлары белән расланган социаль хезмәтләрне күрсәтү сыйфатын бәяләүне үз эченә ала торган документлар. Инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә, халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтүче үзәкләрнең социаль-тернәкләндерү бүлекләрендә стационар һәм ярымстационар хезмәт күрсәтү формасында социаль хезмәт алучыларның тернәкләндерү карталары |
| 13. | Социаль хезмәтләрне алучыларның шәхси әйберләре һәм кыйммәтләре саклануны тәэмин итү | № 442-ФЗ Федераль законның 12 статьясының 1 | Социаль хезмәт алучыларның шәхси әйберләре һәм |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | өлешендәге 12 пункты;<br>ТР МК № 1100 карары белән расланган Стационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 1 бүлеге;<br>ТР МК № 1101 карары белән расланган Ярымстационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 1 бүлеге;<br>ТР МК № 1053 карары белән расланган Өйдә социаль хезмәтләр күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 4.1 пункты | кыйммәтләре саклануны тәэмин итү буенча локаль актлар |
| 14. | Социаль хезмәтләрнең билгеләнгән исемлеге һәм стандартлары нигезендә социаль хезмәтләр күрсәтү буенча таләпләр үтәлеше. | ТР МК № 1100 карары белән расланган Стационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә 1-7 нче кушымталар;<br>ТР МК № 1101 карары белән расланган Ярымстационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә 1-4 нче кушымталар;<br>ТР МК № 1053 карары белән расланган Өйдә социаль хезмәтләр күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 1.3 пункты, 1 нче кушымтасы | Социаль хезмәтләр күрсәтүгә шартнамәләр;<br>Социаль хезмәт алучыларның шәхси эшләре. |
| 15. | Социаль хезмәтләр күрсәткән өчен түләү күләмен хисаплауның дөрес булуы өлешен тикшереп торудан кала, социаль хезмәтләрне түләү, өлешчә түләү яисә бушлай нигездә күрсәтү буенча таләпләрне үтәү | ТР МК № 1100 карары белән расланган Стационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 2.2, 3.2, 4.2, 5.2, 6.2, 7.2 пунктлары;<br>ТР МК № 1101 карары белән расланган | Социаль хезмәтләр күрсәтү турында шартнамәләр |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Ярымстационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 2.2, 3.2, 4.2, 5.2 пунктлары; ТР МК № 1053 карары белән расланган Өйдә социаль хезмәтләр күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 3.1-3.5 пунктлары | |
| 16. | Социаль хезмәтләр күрсәтүнең стационар һәм ярымстационар рәвешендә социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында хезмәтләр алганда социаль хезмәт алучыларга элемтә хезмәтләреннән, шул исәптән «Интернет» челтәреннән һәм почта элемтәсе хезмәтләреннән файдалану мөмкинлеге бирү | № 442-ФЗ Федераль законның 12 статьясындагы 1 өлешенең 9 пункты | Социаль хезмәтләр белән тәэмин итүченең локаль актлары |
| 17. | Социаль хезмәт күрсәтү оешмасында яшәүче ир белән хатынга изоляцияләнгән торак бүлмә бирү | № 442-ФЗ Федераль законның 12 статьясындагы 1 өлешенең 10 пункты | Социаль хезмәтләр белән тәэмин итүченең локаль актлары |
| 18. | Социаль хезмәт алучылар өчен законлы вәкилләргә, адвокатларына, нотариусларга, иҗтимагый һәм (яисә) бүтән оешмалар вәкилләренә, руханиларга, шулай ук туганнарына һәм башка затларга көндезге һәм кичке вакытта алар янына иректә рәвештә килә алу мөмкинлеген тәэмин итү | № 442-ФЗ Федераль законның 12 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты | Социаль хезмәтләр җиткерүченең локаль актлары. Эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре |
| 19. | Инвалидлар белән эшләүче белгечләргә инвалидлар өчен, аларның организмында булган тотрыклы җитешсезлекләрен һәм яшәешенә бәйле чикләмәләрен исәпкә алып, объектларның һәм хезмәт күрсәтүләрнең үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле мәсьәләләрдә инструктаж уздыру яисә укыту. | Россия Хезмәт министрлыгының 527н боерыгы белән расланган Тәртипнең 3 пункты | Инвалидлар белән эшләүче белгечләргә инвалидлар өчен объектларның һәм хезмәт күрсәтүләрнең үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле мәсьәләләрдә инструктаж уздыру яисә укыту журналы |
| 20. | Инвалидлар өчен объектларның үтемле булу дәрәҗәсен этаплап арттыру чараларын, объектларның һәм хезмәтләр күрсәтүнең инвалидлар өчен үтемле булу | Россия Хезмәт министрлыгының 527н боерыгы белән расланган Тәртипнең 9, | Объектларның һәм хезмәтләр күрсәтүнең инвалидлар өчен |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | паспортлары булу-булмавын, мондый паспортларны алып баруга карата таләпләрнең үтәлүен билгеләү максатларында социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан объектларга тикшерү уздыру | 10 пунктлары | үтемле булуы турында паспорт |
| 21. | Социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан Россия Федерациясе законнарында, Татарстан Республикасы законнарында инвалидлар өчен социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан файдалану мөмкинлеге һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең үтемлелеге өлешендә каралган таләпләрне тәэмин итү, нормаларны һәм кагыйдәләрне үтәү буенча чараларны гамәлгә ашыру:<br>социаль, инженер һәм транспорт инфраструктурасы объектларына, ял итү урыннарына һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләргә каршылыкларсыз үтеп керү өчен шартлар;<br>социаль, инженер һәм транспорт инфраструктурасы объектлары урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, мондый объектларга керү һәм алардан чыгу мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляскадан файдаланып;<br>күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча функцияләре тотрыклы бозылган инвалидларны озата бару һәм социаль, инженер һәм транспорт инфраструктурасы объектларында аларга ярдәм күрсәтү;<br>инвалидларның социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларына каршылыксыз үтеп керә алуын һәм, аларның яшәешендәге чикләмәләрен исәпкә алып, хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алуын тәэмин итү өчен кирәкле җайланмаларны һәм мәгълүмат җиткерү чараларын тиешенчә урнаштыру; инвалидлар өчен кирәкле булган, ишетелә һәм күренә торган мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм Брайльның нокталы шрифтлары белән ясалган текстлы һәм тамгалы башка график мәгълүматларны дубльләштерү, сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;<br>махсус өйрәтелгән булуын раслаучы һәм | 181-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы;<br>126-ТРЗ номерлы ТР Законы;<br>Россия Хезмәт министрлыгының 527н номерлы боерыгы белән расланган Тәртип;<br>Россия Хезмәт министрлыгының 386н номерлы боерыгы;<br>СП 59.13330.2016 кагыйдәләр җыелмасы | Социаль хезмәтләр белән тәэмин итүченең локаль актлары; объектның (бинаның, бүлмәнең яки башка төрле корылманың) һәм анда күрсәтелә торган хезмәтләрнең инвалидлар өчен үтемле булуы паспорты»; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм тормышка ашыру һәм норматив-хокукый җайга салу буенча функцияләрне гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә торган формада һәм тәртиптә бирелә торган документы булганда, социаль, инженер һәм транспорт инфраструктурасы объектларына ияртеп йөрүче этне кертү; халыкка хезмәтләр күрсәтүче оешмаларда эшләүчеләр тарафыннан инвалидларга аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачаулый торган каршылыкларны үтеп чыгарга ярдәм итү инвалидлар йөртә торган транспорт чаралары, мондый инвалидларны һәм (яки) инвалид балаларны йөртә торган транспорт чараларын түләүсез урнаштыру өчен урыннарның кимендә 10 проценты күләмендә (кимендә бер урын) парковка урыны бүлеп бирү | | |

3.3 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

«Министрлыкта килгән мөрәҗәгатьләрдә һәм гаризаларда (авторы расланмаган мөрәҗәгатьләрдән һәм гаризалардан тыш), дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан алынган мәгълүматларда бәян ителгән зарури таләпләрне бозуларның әзерләнеп ятуы яисә бозылу билгеләре хакында мәгълүматлар булганда, әгәр зарури таләпләр бозылуның гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян китерүе турында яки күрсәтелгән нәтиҗәләр барлыкка килү куркынычын тудыру турында расланган белешмәләр булмаса, Министрлык юридик затка, шәхси эшкуарга зарури таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтү белдерә һәм юридик затка, шәхси эшкуарга зарури таләпләрнең үтәлүен тәэмин итү буенча чаралар күрергә һәм бу хакта шул кисәтүдә билгеләнгән чорда Министрлыкка хәбәр итәргә тәкъдим итә.»;

5 бүлектә:

5.1.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре резидентларына карата күзәтчелек һәм контроль әлеге Административ регламент нигезендә һәм 473-ФЗ номерлы Федераль законның 24 статьясында, РФ Хөкүмәтенең 1132 номерлы карарында, Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 817 номерлы боерыгында билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла.»;

5.6.3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Административ регламентның 5.6.4 пунктында күрсәтелгән планнан тыш тикшерү барышында Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 19.5 статьясының 1 өлешендә каралган хокук бозу – күрсәтмәнең үтәлмәве (шул исәптән, әгәр күрсәтмәне үтәү турындагы мәгълүмат күрсәтмәне үтәү вакыты

узганчыга кадәр җиткерелмәгән булса яисә билгеләнгән срокта күрсәтмәнең үтәлгәнлеген дәлилләмәсә), йә планнан тыш тикшерү барышында социаль хезмәтләр белән тәэмин итүче тарафыннан Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 19.4 статьясының 1 өлешендә, 19.4.1 статьясының 1 өлешендә каралган хокук бозуларның кылынуы ачыкланганда, яки әлеге Административ регламентның 2.4.2 пунктының 2 һәм 3 пунктчаларында каралган нигезләрдә уздырыла торган планнан тыш тикшерү барышында Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 9.13, 19.6, 19.7 статьяларында каралган хокук бозулар ачыкланган очракта, административ хокук бозу турындагы эшләр буенча беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи зат:

- административ хокук бозу турында эш кузгата – Административ хокук бозулар турында РФ кодексы күздә тоткан тәртипкә туры китереп, Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 9.13 статьясында, 19.4 статьясының 1 өлешендә, 19.4.1 статьясының 1 өлешендә, 19.5 статьясының 1 өлешендә, 19.6 статьясында йә 19.7 статьясында каралган административ хокук бозулар турында беркетмә төзи;

үтәү вакыты: хокук бозуны ачыклаганнан соң кичекмәстән; күрсәтмә үтәү турында мәгълүмат тапшырылмаган очракта – күрсәтмәне үтәү чоры тәмамланганнан соңгы эш көне дәвамында;

- үзләренә карата административ хокук бозу турында эш кузгатылган физик затка яисә юридик затның законлы вәкиленә административ хокук бозу турында беркетмә белән танышып чыгу мөмкинлеген бирә (күрсәтелгән затлар беркетмә эчтәлеге буенча аңлатмалар һәм кисәтүләр бирергә хокуклы, алар беркетмәгә теркәп куела);

- үзенә карата административ хокук бозу турында беркетмә төзелгән затка беркетмәнең күчермәсен җибәрә (заказлы почта юлламасы итеп, кулга тапшыру турында хәбәр итеп яки факсимиль элемтә чараларыннан файдаланып, яки электрон почта буенча);

үтәү вакыты: беркетмә төзелгәннән соң өч календарь көне эчендә;

- административ хокук бозу турындагы эшне карау өчен административ хокук бозу турында беркетмә җибәрә:

гомуми юрисдикция судына (кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы белән) – Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 19.4 статьясының 1 өлешендә, 19.4.1 статьясының 1 өлешендә, 19.5 статьясының 1 өлешендә, 19.6 статьясында яисә 19.7 статьясында каралган эшләр буенча административ хокук бозулар турында;

министрга (министр урынбасарына) – Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 9.13 статьясында каралган административ хокук бозулар турындагы эшләр буенча (социаль хезмәт күрсәтү объектларының һәм социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү таләпләрен үтәүдән читләшү өлешендә);

үтәү вакыты: беркетмә төзелгәннән соң өч тәүлек эчендә;

- үзенә карата административ хокук бозу турында беркетмә төзелгән заттан аның эчтәлеге буенча аңлатмалар яки кисәтүләр алынган очракта, аларны түбәндәгеләргә җибәрә:

административ хокук бозу турында эшне караучы гомуми юрисдикция судына (кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы белән);

министрга (министр урынбасарына) – Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 9.13 статьясында каралган административ хокук бозулар турындагы эшләр буенча (социаль хезмәт күрсәтү объектларының һәм социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү таләпләрен үтәүдән читләшү өлешендә);

үтәү вакыты: мондый аңлатмалар яки кисәтүләр алынганнан соң турыдан-туры;

- административ хокук бозу турында беркетмә күчермәсен тикшерү материалларына терки;

үтәү вакыты: административ хокук бозу турындагы беркетмә (беркетмәнең эчтәлеге буенча аңлатмалар яки кисәтүләр) гомуми юрисдикция судына, яки Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 9.13 статьясында каралган административ хокук бозулар турындагы эшләр буенча беркетмәләр (социаль хезмәт күрсәтү объектларының һәм социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү таләпләрен үтәүдән читләшү өлешендә) министрга (министр урынбасарына) җибәрелгәннән соң бер эш көне эчендә.»;

5.6.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Зарури таләпләр бозылуны бетерү буенча чаралар күрү» административ процедураның нәтиҗәсе түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

- зарури таләпләрнең ачыкланган бозуларын бетерү турында күрсәтмә;

- Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 19.4 статьясының 1 өлешендә, 19.4.1 статьясының 1 өлешендә, 19.5 статьясының 1 өлешендә, 19.6 статьясында яисә 19.7 статьясында каралган административ хокук бозу турында суд органына җибәрелгән беркетмә;

- Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 9.13 статьясында каралган административ хокук бозу турында (социаль хезмәт күрсәтү объектларының һәм социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү таләпләрен үтәүдән читләшү өлешендә) министрга (министр урынбасарына) тапшырылган беркетмә;

түбәндәге эчтәлекле 5.6.5 пункт өстәргә:

«5.6.5. Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резиденты планнан тыш тикшерү уздырылганчыга кадәр зарури таләпләрнең ачыкланган бозуларын бетерү турында күрсәтмәне үтәмәгән очракта, эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү өзелергә һәм алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резиденты статусы вәкаләтле федераль органның гаризасы нигезендә суд карары нигезендә туктатылырга мөмкин.»;

7 бүлектә:

7.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.4. Әгәр язмача шикаятьтә юридик затның аталышы (мөрәҗәгать итүче юридик зат булганда), шикаятьне җибәргә мөрәҗәгать итүченең фамилиясе яки җавап җибәрелергә тиешле почта адресы күрсәтелмәсә, шикаятькә җавап бирелми. Әгәр дә күрсәтелгән шикаятьтә хокукка каршы килә торган гамәлнең әзерләнүе, кылынуы яки кылынганлыгы турында, шулай ук аны әзерләүче, кылучы яки кылган зат турында белешмәләр булса, шикаять компетенциясенә ярашлы рәвештә дәүләт органына җибәрелергә тиеш.

Әгәр язмача шикаятьтә цензурасын яки мыскыллау сүзләре, вазыйфаи затның, шулай ук аның гаилә әгъзаларының гомеренә, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янаулар булса, шикаять анда куелган мәсьәләләрнең асылы буенча җавапсыз калдырылырга мөмкин. Бу очракта шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә хокуктан явызларча файдалануның ярамаганлыгы турында хәбәр ителә.

Әгәр язмача шикаятьнең тексты укылышлы булмаса, шикаятькә җавап бирелми, һәм ул карау өчен дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка аларның компетенцияләренә туры китереп җибәрелергә тиеш түгел, бу хакта шикаятьне теркәү көненнән башлап җиде көн эчендә шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә, әгәр аның фамилиясе һәм почта адресы укылышлы булса.

Әгәр язмача шикаять тексты шикаятьнең асылын ачыкларга мөмкинлек бирмәсә, шикаятькә җавап бирелми һәм ул ул карау өчен дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка алар компетенциясенә туры китереп җибәрелергә тиеш түгел, бу хакта мөрәҗәгатьне теркәүгә алган көннән соң җиде көн эчендә шикаятьне җибәргән затка хәбәр ителә.

Язмача шикаятьтә аның асылы буенча элек җибәрелгән шикаятьләргә бәйле рәвештә инде берничә мәртәбә язмача җаваплар бирелгән сорау бәян ителгән булса һәм шул ук вакытта шикаятьтә яңа дәлилләр яисә шартлар китерелмәсә, министр, Министрлыкның вазыйфаи заты яки моңа вәкаләтле заты күрсәтелгән шикаятьнең һәм элек җибәрелгән шикаятьләрнең Министрлыкка яисә Министрлыктагы шул бер үк вазыйфаи затка җибәрелгән булуы шарты белән, чираттагы шикаять белән мөрәҗәгать итүнең нигезсез булуы һәм әлеге мәсьәлә буенча мөрәҗәгать итүче белән мондый язышуны туктату турында карар кабул итәргә хокуклы. Әлеге карар турында шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә.

Министрлыкка яки Министрлыкның вазыйфаи затына, 59-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясының 4 өлешенә туры китереп, Министрлыкның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында җавабы урнаштырылган сорауны үз эченә алган язмача шикаять килгән очракта, шикаятьне җибәрүче затка шикаятьне теркәүгә алган көннән соң җиде көн эчендә, шикаятьтә куелган сорауга җавап урнаштырылган Министрлыкның рәсми сайтының электрон адресы турында хәбәр ителә, бу вакытта суд карарына шикаять белдерелә торган шикаять кире кайтарылмый.

Әгәр шикаятьтә күтәрелгән мәсьәләнең асылы буенча дәүләт серен яисә федераль законда саклана торган бүтән серне тәшкил итүче белешмәләрне таратмыйча җавап биреп булмаса, шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә

күрсәтелгән белешмәләрне таратуның мөмкин булмавына бәйле рәвештә куелган мәсьәләнең асылы буенча җавап бирү мөмкинлеге булмау турында хәбәр ителә.

Суд карарына шикаять белдерелгән шикаять теркәлгән көненнән башлап җиде көн дәвамында, әлеге суд карарына шикаять белдерү тәртибен аңлатып, мөрәҗәгать итүчегә кире җибәрелә.

Шикаятьтә күтәрелгән мәсьәләләрнең асылы буенча җавап бирү мөмкинлеге булмаган сәбәпләр алга таба бетерелсә, мөрәҗәгать итүче шикаятьне Министрлыкка яисә Министрлыкның тиешле вазыйфаи затына кабат җибәрергә хокуклы.»;

7.5 пунктта «шикаять бирү» сүзләреннән алда «карарларына,» сүзен өстәргә;

әлеге Административ регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән дәүләт функциясен үтәүнең блок-схемасында:

«административ хокук бозу турында беркетмәне суд органына җибәрү» сүзләрен «Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 19.4 статьясының 1 өлешендә, 19.4.1 статьясының 1 өлешендә, 19.5 статьясының 1 өлешендә, 19.6 статьясында яисә 19.7 статьясында каралган административ хокук бозу турындагы беркетмәне суд органына, Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 9.13 статьясында каралган административ хокук бозу турында беркетмәне (социаль хезмәт күрсәтү объектларының һәм социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү таләпләрен үтәүдән читләшү өлешендә) җибәрү» сүзләренә алмаштырырга.